**Хәмзә абый турында.**

Адәм баласы дөньяга килә...Аны анда ниләр көтә, бер аллаhы гына белә, диләр. Картлар әйтүенчә - адәм баласы дөньяга туганда ук аның язмышы билгеләнә, шуңа күрә әйтеләдер дә инде - язмыштан узмыш юк, дип.

Хәмзә абыем да дөньяга килгәндә башына да китермәгәндер - ничек аның тормыш юлы булыр, алда нәрсәләр көтәдер, нинди сынамышлар, нинди язмышлар? Андый нәрсәләр турында уйлау аның башында бөтенләй дә булмагандыр. Алтмыш җиде ел яшәү чорында ул тырышты, тырмашты, кеше арасында төшеп калганнардан чутланмаска, кешечә яшәргә, көченнән килгәнчә эшләргә, hәрвакыт файдалы эшләр белән мәшъгуль булырга, сәламәт булганда тырышырга, бер минутны да бушка уздырмаска - аның бөтен омтылышы шул иде.

Ләкин дөнья үз сынауларын китереп кенә тора. Гаилә тормышы бозыла. Үзенең көче белән җиткергән йортыннан чыгып китәргә мәҗбүр була абыем. Шәhәрдәге фатирда яшәү, гел дә тик тормыйча эш эшләп өйрәнгән абыйга эшсез яту аның күңеленә бер дә охшамый. Шуңа ул шушы хәлдән чыгу өчен планнар кора башлый. Үзенең планнары белән бүлешергә, миннән киңәш көтеп, еш кына очраша идек аның белән. Күп кенә планнары миңа охшамый иде, ул да минем белән ризалаша. Озак та үтмәде, Менделеевск шәhәрендәге квартирасын Ижёвка авыл өенә алыштырды. Билгеле, үзе төзегән өй булмагач, күп нәрсәне кире сүтеп корырга, каралты-коралар җитми - менә абыйның алдында шундый планнар туа. Тиз арада гараж җиткерү, өй эчендә үзгәрешләр ясау - бу беренче планда. Ул вакытта абый пенсиягә чыга. Әмма ул тырыша, тырмаша, алга куйган планнарын үти. Тик йортта хуҗа хатыны булмау белән абый килешә алмый. Менә ул Зәния исемле үзеннән унике яшькә яшь хатын белән таныша. Зәния ул вакытта Ижминводы санаториенда эшли. Бик матур гына тормыш корып җибәрәләр алар бергә. Хәмзә абый яшәреп киткәндәй булды шул чорда, бәхетле итеп тойгандыр инде ул үзен. Шунлыктан ул Зәния белән рәсми рәвештә никахлаша. Шушы хәлне ишетеп, абыйның беренче хатыны Рәйсә апа Зәниянең телефон номерын белеп шалтырата hәм әйтә: Син сөенмә, законлы никахлы хатын булдым дип, Хәмзә үлсә, бөтен мал-мөлкәте аның малайларына була. Бу сүзләр Зәниянең йөрәгенә таш булып бәрелә, кәефләре киткәнен күреп, Хәмзә абый аннан сораганнан соң, аны тынычландырырга тырышып: Ярар, мин сиңа завещание ясармын,- дип әйтткән. Әйткән hәм эшләгән дә - бар мөлкәтен Зәниягә васыять иткән.

Тора-бара аралар бозыла башлаган. Моңа сәбәпләр булмыйча калмагандыр. Һәркайсының үз балалары бар, ә Зәниянең балалары (бигрәк тә кызы) еш күренәләр бу йортта. Күршеләренә "яшь" гаиләнең хатыны кызына фатир алырга булышуы мәгълум. Кредитка алган акчаны Хәмзә абый түләп барган, диләр. Ә бу анда үз балалары мәнфәгате санга сугылмый дигән уй тудырырга мөмкин. Ни дисәң дә, һәркемнең үзенеке якынрак бит. Хәмзә абыйның сөйләгәне булды - елга бер улы Марат хәлне белергә килә икән, ул да тавышка керә. Абый һаман да, тормыш көйләнер әле, дигән уй белән яшәгәндер инде, Зәниягә Ока машинасы алып бирә; Зәния үзе дә сөенеченнән шул Окага утырып Бәзәкәгә килеп Искәндәр абый янына кереп, миңа Хәмзә машина алып бирде, дип мактанып ала. Җир җиләге җиткән вакытларда икесе бергә иртән-иртүк җиләк җыеп, Зәния җиләкләрне стаканлап санаторийда сатып утырган. Бик күп кенә тавык чебиләре үстергәннәр.

Ләкин каршылыклар барыбер көчәйгәннән көчәя барган, һаман да шул балалар аркасында, бигрәк тә Зәниянең кызы аркасында булгандыр. Хәмзә абыйның әйткәне булды миңа: кызы кияүгә чыкса, сирәгрәк кайтып йөрер иде. Соңгы вакытларда, абый минем белән очрашканда, Зәниянең Менделеевск больницасына кереп ятуын әйтте. Мин сорагач - кайсы җире авырта соң аның? Хәмзә абый миңа кызыклы хәбәр әйтте - Зәния шизофрения диагнозы (психик авыру) алырга йөри. Мин тагы сорадым - ә нәрсә өчен кирәк соң ул аңа? Хәмзә абый төпле генә җавап бирмәде, әллә белмәгән, әллә белеп тә әйтәсе килмәде миңа.

Зәния янына больницага еш йөрде Хәмзә абый. Менә икенче март, җомга көнне (2012 елның) кич белән Ижёвкага өйгә кайтырга кирәк дигән сылтау белән Зәния Хәмзә абыйны больницага килүен сорый. Хәмзә абый үзенең "Ода" машинасы белән килеп җитә; аларның икәүләп больницадан чыкканы видеокамерага эләгә. Ни хикмәт, шунда ук Зәниянең яшертен очрашып йөри торган ир кешесе Таһир Кантюков та була. Сүз уңаеннан әйтеп китим, миңа бу хәл соңнан гына билгеле булды. Зәния белән бу Таһир күп еллар элек дуслаша; Зәния санаторийда санитар булып эшли, ә Таһир - анда ведомстводан тыш сак милициясе хезмәткәре. Инде соңгы вакытта милиционер Таһир ялга китеп Зәния кияүгә чыккач та, җылы мөнәсәбәтләр дәвам итүе телефоннан еш аралашып тору аңлата. Шул 2 нче март көнне дә алар берничә мәртәбә телефоннан сөйләшкәннәр. Бер хатынның законлы һәм яшертен ике иренең больница ишегалдында очрашуын очраклы хәл дип юрарга мөмкин. Ләкин алга таба бу "очраклык"лар бер кич өчен артык күбәеп китә. Таһирның төнгә каршы Бәзәкәдә йомышы булуы ачыклана һәм ул элек ук таныш булган (бер мәлне абый эшләгән подстанциядә Таһир

ведомстводан тыш сак милициясе хезмәткәре булып эшли, әле, җитмәсә, абый сменасында алар бергә чәй дә эчкәлиләр) Хәмзә абыйдан юл уңаенда утыртып баруын сорый. Шулай бергәләп кузгалып китеп шәһәрне чыккач, аулак караңгы урында, Зәния, нindидер сәбәп табып, туктарга куша. Ул машинадан чыгуга арткы утыргычта утыручы Таһир алдан әзерләп куелган чүпрәккә төрелгән авыр таш белән абыйның башына суга. Башына таш белән суга торгач җан әсәре калмаган гәүдәне арткы утыргычка күчереп салгач, Таһир рульгә үзе утыра һәм мәеттән котылу максатында  чүп базасына (Макаровка свалкасына) юл тоталар; төнлә китереп аударылган чүп-чар өемнәре астында калып юкка чыгар, дип планлаштырганнар, күрәсең. Ләкин абыйның сулышы, ыңгырашуы сизелә. Шуннан соң, кыйнап-кыйнап та үлә алмаган абыйны юлга салып, үз машинасы белән таптаталар. Бу кадәресе план буенча барса да, свалка юлында “Ода” батып кала. Мәетне кырга өстерәп, өстенә аннан-моннан кар сипкәлиләр дә, машинаны калдырып кайтып китәләр җәяүләп Менделеевскига. Хатын больницага, үз палатасына кереп китә. Шул вакытта аның белән больницада яткан кешеләр сөйләве буенча, Зәния канга буялган киемнәрне юып ала.

Өченче март көнне иртән иртүк полигон юлында чүп-чар илтүче “КАМАЗ” шофёры хуҗасыз сәер туктап калган “Ода” машинасын күрә.Әллә ни игътибар бирмичә узып китсә дә, көндезен туктап күз салырга була; кан таплары күргәч, полициягә хәбәр итә. Тиздән мәет тә күзгә ташлана. Полиция машина номеры белән тиз арада бу хәлне ачыклый. 4 нче мартта  исә шикле кеше - 1957 нче елгы абыйның хатыны Зәния тоткарлана.Тикшерүләр барышында Зәния, күпме генә үзенең бу эшкә катнашмасы юклыгын дәлилләргә тырышса да, курткада юылып бетмәгән кан табы буенча, аның гаепле булуы тиз ачыклана. Мин больницада идем, диюе дә видеокамерадагы сүрәт буенча ачыклана. Шуннан соң ул, гаебен танып, күрсәтмә бирә. Бу җинаятне эшләүнең сәбәбе нәрсәдә? - дип сорагач, Зәния - тапкан малны бүлешәсем килмәде, - дип  җавап биргән. Ләкин ул үзенең күрсәтмәләрендә бу явызлыкларны (ничек җәберләп үтергәннәрне күрсәтеп) берүзе башкаруы турында әйтә. Моңа тикшерүчеләр ышанып бетми, бу хәл хатынның аңламыйча, белештермичә (Зәния сүзләре буенча) кылган гамәленә охшамаган.  Сәламәтлеге бик нык булмаган 55 яшьлек хатын өчен көч җитмәслек гамәл икәне аермачык була. Соңгы вакытта  Зәния белән телефоннан аралашкан кешеләр тикшерелә. Өч тәүлек дигәндә, Таһир Кантюков тоткарлана. Зәния дә, Таһир да яхшы аңлаганнар. Әгәр дә икәүләп башкарылган җинаять дип исбат ителсә, аларның һәрберсе дә 22 шәр елга

хөкем ителәсе. Ә бу хәлне бигрәк тә нык белүче элек милиция хезмәткәре булган Т.Кандюков.

Март аенда Зәния Минзәлә төрмәсенә җибәрелә. Озак та үтми, ул изолятор камерасында асылынып үлә. Гаеплеләрнең берсе юк булу тикшерү эшләренә йогынты ясамый калмый. Бу Т.Катюков язмышын җиңеләйтүгә дә күпмедер дәрәҗәдә ярдәм итә. Чөнки башка төрле сөйләүче юкка чыга. Шул сәбәпле Зәния китергән дәлилләр төшеп кала. Нәтиҗә буларак, җинаятьнең төркем белән эшләнүен исбатлау кыенлаша. Ахыр чиктә, Т.Кантюков суд каршына ялгызак үтерүче булып баса һәм җәзаның да чагыштырмача җиңелен ала.

Шулай бик кызу башланган эшне тикшерү бик озакка сузыла. Яз башында булган вакыйгага ноктаны суд бары тик көз азагында гына куя һәм.. бөтенләй башка кеше хөкем ителә.

Шунысы бик аянычлы - тормышны бик тә нык яраткан, җанын, тәнен биреп яшәргә тырышкан абыемның гомере шундый кәбахәт кеше кулыннан өзелү, җәберләп үтерелү... Күп сораулар ачыкланмыйча калды. Ничек Хәмзә абый сизенмәде икән шундый куркыныч кеше белән тормышын бәйләгәнен? Шул турыда сөйләшүләр алып барганда миңа җиткерделәр - ләбаса абыйны кисәткән булганнар икән - сак бул, Зәния беренче ирен дә үзе генә үтерде, дигәч, Хәмзә абый: мин каршы тора алырмын, тик агу бирсә генә белмәм, - дигән. Шундый кисәтүләрне нишләп уена алмады икән ул? Нишләп тизрәк ул Зәниягә биргән завещаниесын юкка чыгармаган?

Тагы да шунысы аңлашылмаслык, башка сыярлык түгел - алты ай узганнан соң бөтен мал-мөлкәте үзен үтерүченең кызына булды...

Мондый аянычлы хәлләрне күрергә язмасын, бу гыйбрәт хәл булып калсын исәннәргә. Начарлык эшләсәң кешегә - үзеңә тагы да начаррак булып кайтыр!

*Гүзәл Габдуллина-Гыйльфанова, 2018ел.*